**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 июнь № 434

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 22 май, 347 нче; 2015 ел, 14 август, 589 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын

төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тәртипнең гамәле җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан түбәндәге шартларга туры килә торган чикләрендә кишәрлекләрдән файдалануга тарала:

1) җир кишәрлеге астындагы җир асты байлыклары кишәрлегендә дәүләт балансында саналган гомумтаралган файдалы казылмалар юк;

2) җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә геология тыюлыгы, табигать яки мәдәният тыюлыгы яисә һәйкәле дип игълан ителмәгән, федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияләргә, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге авыл хуҗалыгы җирләренә кертелмәгән, су саклау зоналарыннан читтә урнашкан;

3) җир асты кишәрлеге геология өйрәнүе, разведкалау һәм файдалы казылмалар чыгару максатлары өчен җир астыннан файдалану хокукына лицензия нигезендә башка җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелмәгән;

4) җир асты кишәрлеге Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы раслаган файдалануга бирү өчен тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы буенча җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җир асты кишәрлекләре белән кисешми;

5) җир асты кишәрлегендә урнашкан көнкүреш коелары һәм скважиналары урнаштыру һәм аларны эксплуатацияләү күздә тотылган сулы горизонт үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булмый.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы соратуда күрсәтелгән җир кишәрлегенең әлеге Тәртипнең 2 пункты шартларына туры килүен килештерү һәм билгеләү буенча эшне билгеләнгән тәртиптә оештыра, шул исәптән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органнары белән дә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органнарының соңгы бәяләмәсен алган көннән соң биш эш көне эчендә җир кишәрлеге милекчесенә, җирдән файдаланучыга, җир хуҗасына яки җир кишәрлеген арендага алучыга җир асты кишәрлегенең әлеге Тәртипнең 2 пунктына туры килүе яки туры килмәве турында язмача мәгълүмат бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков